Мөслим авыл җирлеге Советы
карары

2025 елның 27 марты № 59/3

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советының 2025 елның 12 февралендәге 57/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын билгеләү һәм гамәлгә кертү турында» 2024 елның 27 ноябрендәге 57/1 номерлы карарын юкка чыгару хакында» 2025 елның 12 февралендәге 53/1 номерлы карарына, түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:
«1.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясындагы 4 пункты нигезендә әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.».
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чистай муниципаль районы
Мөслим авыл җирлеге башлыгы Л.З. Хәбибуллина